**Шәһәр күләмендә физика фәненнән татар телендә үткәрелә торган**
**олимпиаданың мәктәп этабы җаваплары**
**2025-2026 нчы уку елы**
**10 нчы сыйныф**

**Гомуми балл - 50**

**1.** Һавасын бик тиз рәвештә суырып чыгарып була торган савытта m *г* массалы су бар. Суның температурасы t = $0^0$C. Интенсив рәвештә парга әверелү нәтиҗәсендә су, катып, бозга әйләнә. Суның башлангыч массасының нинди өлеше бозга әйләнгән?

**В сосуде, из которого быстро откачивают воздух, находится вода массой m *г* при температуре *t* = $0^0$C. В результате интенсивного испарения происходит замораживание воды. Какая часть первоначальной массы воды обратилась в лед?**

**Чишү:** Паръясалу өчен кирәкле энергия суны катырганда аерылып чыккан энергия исәбеннән табылырга мөмкин.
Әгәр $m_1$ - хасил булган бозның массасы, ә $m_2$ - пар массасы, ул вакытта суның массасы катканчы: $m = (m_1 + m_2)$ булган (**1 балл**).
Массасы $m_1$ булган суны кристаллаштырганда бүленеп чыккан җылылык микъдары $Q_1 = \lambda \cdot m_1$ (**2 балл**).
Массасы $m_2$ булган суны парга әйләндерү өчен, кирәкле җылылык микъдары $Q_2 = L \cdot m_2$( **2 балл**).
Энергияне саклау законы нигезендә түбәндәгеләрне язарга мөмкин:
$\lambda \cdot m_1 = L \cdot m_2$ (**2 балл**).
$\lambda \cdot m_1 = L \cdot (m - m_1)$ (**1 балл** ), моннан чыгып: $m_1 = L \cdot m/(L + \lambda) \approx 0{,}87m$(**2 балл**).
**Җавап:** Бу башлангыч су массасының 87% була.

2. 125 м биеклектән ирекле төшүче таш, хәрәкәт итүенең соңгы секундында нинди юл үтәр?

| | |
|---|---|
| Бирелгән:<br>$h = 125$ м<br>$\Delta t = 1c$ | Чишү: 80 м биеклектән ирекле төшү вакытын табабыз:<br>$h = \frac{gt^2}{2} \Rightarrow t = \sqrt{\frac{2h}{g}}$ **(2 балл)** |
| S=? | Соңгы секунд алдыннан ташның башлангыч тизлеге:<br>$V_0 = g(t - \Delta t) = g\left(\sqrt{\frac{2h}{g}} - \Delta t\right) = \sqrt{2gh} - g\Delta t$ **(3 балл)**<br>Соңгы секундта үткән юлны билгелибез:<br>$S = V_0\Delta t + \frac{g\Delta t^2}{2} = \sqrt{2gh}\Delta t - \frac{g\Delta t^2}{2} = \Delta t(\sqrt{2gh} - \frac{g\Delta t}{2})$ **(4 балл)**<br>$[S] = с \cdot \left(\sqrt{{}^{м}/_{с^2} \cdot м} - \frac{{}^{м}/_{с^2} \cdot с}{1}\right) = с \cdot \left(\frac{м}{с} - \frac{м}{с}\right) = с \cdot \frac{м}{с} = м$<br>$S = 1 \cdot \left(\sqrt{2 \cdot 9{,}8 \cdot 125} - \frac{9{,}8 \cdot 1}{2}\right) = 45$ (м) **(1 балл)** |
| Җавап: | 45 м |

3. Горизонтка авышлык почмагы α = 30° тигез булган яссылык өстендә массасы m = 20 кг булган таш ята. Ташны яссылык буйлап F = 10 Н көч куеп аска таба тартып төшергәндәге ышкылу коэффициентын исәплэгез.

| | |
|---|---|
| **Бирелгән:**<br>m = 15 кг<br>α = 30°<br>F = 10 Н<br>g = 10 м/с$^2$ | **Чишү:**<br> |
| μ-? | Ньютонның 1-нче законы буенча:<br>$\vec{F} + \vec{F}_{тр} + \vec{N} + \overrightarrow{mg} = 0$ **(1 балл)** |

| | |
|---|---|
| | $ox: F\cdot cos\alpha - F_{тр} + mg\cdot sin\alpha = 0$ **(1 балл)**<br>$oy: F\cdot sin\alpha + N - mg\cdot cos\alpha = 0$ **(1 балл)**<br>$F_{тр} = F\cdot cos\alpha + mg\cdot sin\alpha$ **(1 балл)**<br>$N = mg\cdot cos\alpha - F\cdot sin\alpha$ **(1 балл)**<br>Ышкылу көчен табабыз: $F_{тр} = \mu\cdot N \Rightarrow \mu = \frac{F_{тр}}{N}$ **(1 балл)**<br>$\mu = \frac{F\cdot cos\alpha + mg\cdot sin\alpha}{mg\cdot cos\alpha - F\cdot sin\alpha}$ **(2 балл)**<br>$\mu = \frac{10\cdot cos30° + 15\cdot 10\cdot sin30°}{15\cdot 10\cdot cos30° - 10\cdot sin30°} = 0{,}66$ **(2 балл)**<br>$\mu < 1$ |
| **Җавап:** | $\mathbf{0,66}$ |

4. Җылыткыч каршылыклары $R_1 = R_2 = R$, $R_3 = 3R$ булган 3 элементтан тора. Алар үзара схемада күрсәтелгәнчә тоташтырылганнар. Җылыткыч A һәм B клеммаларына тоташтырылган. Әгәр 15 секунтта $R_1$ каршылыгында $Q_1 = 160$ Дж җылылык микъдары бүленеп чыкса, 1 минутта $R_3$ каршылыгында нинди җылылык микъдары бүленеп чыгар?




| | |
|---|---|
| **Бирелгән:**<br>$R_1 = R_2 = R$<br>$R_3 = 3R$<br>$t_3 = 1мин = 60$ с<br>$t_1 = 15с$<br>$Q_1 = 160$ Дж | **Чишү:** Джоуль-Ленц законы буенча:<br>$Q_1 = I_1^2 R_1 t_1$ **(1 балл)**<br>$Q_3 = I_3^2 R_3 t_3$ **(1 балл)**<br>$R_2$ һәм $R_3$ каршылыклары үзара параллель тоташтырылганнар һәм $R_1$ каршылыгы алар белән эзлекле тоташтырылган, шуның өчен<br>$I_1 = I_2 + I_3$ **(1 балл)** һәм $U_2 = U_3$ **(1 балл)** яки Ом законы буенча $I_2 R_2 = I_3 R_3$, **(1 балл)** моннан<br>$I_3 = \frac{I_2 R_2}{R_3} = \frac{I_2 R}{3R} = \frac{1}{3} I_2 = \frac{1}{4} I_1$ **(2 балл)**<br>$Q_3 = \left(\frac{1}{4} I_1\right)^2 3R_1 t_3 = \left(\frac{1}{4} I_1\right)^2 3R_1 t_1 \frac{t_3}{t_1} = \frac{3}{16} Q_1 \frac{t_3}{t_1}$ **(2 балл)**<br>$Q_3 = \frac{3}{16}\cdot 160\cdot\frac{60}{15} = 120$ (Дж) **(1 балл)** |
| $Q_3$=? | |
| **Җавап:120 Дж** | |

5. Җир өслегеннән нинди биеклектә очканда ясалма иярченнең тизлеге 7,6 км/с булыр? Бу иярченнең әйләнү периодын табыгыз.

| | |
|---|---|
| **Бирелгән:**<br>$R_3 = 6400$ км=$6{,}4\cdot 10^6$ м<br>$M_3 = 6\cdot 10^{24}$кг<br>$G = 6{,}67\cdot 10^{11}\frac{Н\cdot м^2}{кг^2}$<br>$V = 7{,}6\frac{км}{с}$ | **Чишү:**<br>Җир өстеннән $R$ биеклегендә иректе төшү тизләнеше:<br>$g = \frac{G\cdot M_3}{(R_3+h)^2}$ **(1 балл)**<br>Ирекле төшү тизләнеше бу вакытта үзәккә омтылу тизләнешенә тигез:<br>$g = \frac{V^2}{R_3+h}$ **(1 балл)**<br>2 тигезләмәдән $g$ ларны тигезлибез:<br>$\frac{G\cdot M_3}{(R_3+h)^2} = \frac{V^2}{R_3+h}$ **(2 балл)**<br>$V$ тизлеген билгелибез:<br>$V = \sqrt{\frac{G\cdot M_3}{(R_3+h)}}$ **(1 балл)** $V^2 (R_3+h) = GM_3$ |
| $R$ =? $T$ =? | |

| | |
|---|---|
| | $GM_3/V^2 = R_3 + h \Rightarrow (GM_3/V^2 - R_3) = h$ **(1 балл)**<br>h= 520 км<br>Әйләнү хәрәкәте тизлеге:<br>$V = \frac{2\pi(R_3+h)}{T} \quad \Rightarrow T = \frac{2\pi(R_3+h)}{V}$ **(2 балл)**<br>$T = \frac{2 \cdot 3{,}14 \cdot (6{,}4 \cdot 10^6 + 0{,}52 \cdot 10^6)}{7{,}6 \cdot 10^3} = 5{,}718 \cdot 10^3 (c)$<br>$= 95{,}3(\text{мин})$ (**2** балл) |